СӨЙ ГӨМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

9 июль, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 74 (8086) | Бәясе билгеләнгәнчә

## — АНОНС —

**1931 елның 9 июлендә «Дуслык»ның беренче саны дөнья күрә. Газета туган көнгә багышланган язмаларны икенче биттән укыгыз.**

## МОРАТОВКА ТАГЫН БЕР ВАЗИФА

Кичә Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Чаллыда «КамАЗ» акционерлык җәмгыяте директорлары советының утырышында катнашты һәм көн тәртибендәге беренче - оештыру мәсъәләсе буенча җыелышны алып барды. Ул «КамАЗ» ачык типтагы акционерлык җәмгыяте директорлары советы рәисен сайлау буенча үзенең фикерен белдереп (алга таба автогигантның эшен җайга салуда «КамАЗ»га Татарстан Министрлар Кабинеты белән берлектә шактый нык эшләргә туры киләчәк), бу урынга Премьер - министрның беренче урынбасары Р.Моратовны сайларга тәкъдим итте.

М.Ш.Шәймиев элеккеге рәис Н.Бехның 17 еллап монда эшләвенә зур бәя бирде һәм аңа Дәүләт Советы, Татарстан хөкүмәте, камазлылар һәм үз исеменнән рәхмәт белдерде.

Яңа рәис Р.Моратов җитәкчелегендә 1997 елның икенче яртысына әйләнештәге капиталны арттыру өчен инвестицияләр эзләү буенча чаралар тикшерелде.

**«Ватаным Татарстан» газетасыннан.**

## Сессия булды

7нче июльдә халык депутатларының Октябрь район Советының чираттан тыш унберенче сессиясе булды.

Сессияне халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе Ф.С.Сибагатуллин ачты.

Сессиядә түбәндәге мәсьәләләр каралды:

1. Район сайлау комиссиясе рәисенең 22нче Совхоз сайлау округы буенча үткән сайлаулар нәтиҗәләре турында информациясе.
2. Җир кодексы проекты турында.
3. Халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе урынбасары Е.К.Савинов гаризасы турында.
4. Халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе урынбасары вазифаларын йөкләү турында.
5. Халык депутатларының Октябрь район Советы депутатының депутат вәкаләтләрен туктату турында гаризасы турында.
6. Даими комиссия составындагы үзгәрешләр турында.
7. Җирле үзидарә Советлары уставларын раслау турында.

Сессиянең төп мәсьәләсе Татарстан Республикасы Җир Кодексы проектын тикшерүгә багышланган иде. Проект буенча шактый тәкъдимнәр кертелде. Алар Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәреләчәк.

Сессия оешкан төстә үтте.

## Сайлаучылар игътибарына!

7 июльдә үткән район сайлау комиссиясе утырышында 13 нче Дальный сайлау округы буенча халык депутатларының Октябрь район Советына халык депутатын сайлау 1997 елның 20 сентябренә билгеләнде.

## «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

Узган шимбә - якшәмбедә шәһәрләрнең авылга ярдәмгә бердәм булып күтәрелүе гаять нәтиҗәле булды. Шул ике көндә монарчы җәй буена әзерләнгән кадәр яфрак азык тупланды һәм хәзер хуҗалыкларда бу төр кыйммәтле азыкның запасы 800 тоннадан артып китте. Менә бит ул күмәк көч - тау күчерә дигәннең ачык чагылышы.

Башка төр терлек азыклары хәзерләүгә килгәндә, Муса Җәлил исемендәге, Мичурин исемендәге, «Кондырча», «Таң», «Комбайн», «Рассвет», «Родина» хуҗалыкларында бу эштә элеккечә үк зур оешканлык күрсәтәләр. Аларның беренчесендә бер шартлы терлеккә әзерләнгән барлык азык 10 центнер азык берәмлегенә якын инде. «Комбайн» һәм «Таң»да бу күрсәткеч 5,2 - 5,4 центнер азык берәмлеге. Шунысы куанычлы, бу хуҗалыкларның күбесендә коры печән запасы пландагының яртысыннан яки өчтән икесеннән күбрәк инде. Соңгысы МСОның ярдәмче хуҗалыгында да чагыштырмача ишле. Сенаж салуга чын - чынлап тотынган хуҗалыклар саны да арта бара. Кичәге көнгә «Кондырча»да 900, Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта 600, «Киекле» һәм Мичурин исемендәге хуҗалыкларда 500 тоннадан артыграк, РСУның ярдәмче хуҗалыгында 400 тоннадан күбрәк сусыл азык базларга урнаштырылды инде. Шул ук вакытта шикәр заводының һәм сөт - май комбинатының ярдәмче хуҗалыкларында, Хафизов исемендәге, «Үрнәк» КХАларында бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык берәмлеге ике центнер тирәсе генә әле.

## Үзәктә - уракка әзерлек

Бүген район кырларында өлгереп килә торган игеннәрнең гадәттән тыш мул уңыш вәгъдә итүе никадәр куандырса, аны оешканлык белән һәм югалтуларсыз җыеп алуның мәшәкатьсез генә булмаячагы шулкадәр үк борчый. Шуңа күрә, уракка санаулы гына көннәр калып барганда бу мөһим кампаниягә әзерлекнең ни дәрәҗәдә булуы, җитешсезлекләрне тиз арада бетерү зарурлыгы турында сөйләшү өчен узган якшәмбе көн хуҗалыклар, аларга шефлык итүче предприятие һәм оешма җитәкчеләре, агропромышленностька хезмәт күрсәтүче служба башлыклары, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең баш белгечләре катнашында район хакимиятендә махсус киңәшмә уздырылуы очраклы гына түгел иде.

Хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев киңәшмәне ачып бүген авыл хуҗалыгында гаять җаваплы имтихан якынлашуын ассызыклап, урыннарда урак техникасын, беренче чиратта сугу комбайннарын соңгысына кадәр төзәтеп бетерү турында иң элек хуҗалыкларның үзләрендә кайгыртырга, шул ук вакытта аларга шефлык итүче предприятиеләр һәм оешмалар да кулларыннан килгән барлык ярдәмне күрсәтергә тиешләр дип басым ясап үтте. Мәсьәләнең бар кискенлегендә куелуы юкка түгел, чөнки районда исәптә торган 367 бөртекле ашлык комбайнының өчтән бере бүгеннән кырга чыгарлык дәрәҗәдән ерак тора әле. Уракта иң зур өмет багълана торган куәтле ДОНнар белән дә хәл шундыйрак. Дөрес, урак турында алдан кайгыртып, комбайннарны ремонтлау эше белән кыш буе шөгыльләнгән хуҗалыкларда хәл яхшы. «Родина»да комбайннарның барысы да уракка әзер бүген, «Кондырча»да, «Заря» кооперативлар берлегендә, РСУның ярдәмче хуҗалыгында һәм кайбер башка хуҗалыкларда берәр генә комбайнны төзәтеп бетерәсе бар. Ә менә М.Җәлил исемендәге, «Алга», «Комбайн» КХАларында, шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгында һәм тагын берничә хуҗалыкта хәл мактанырлык түгел әле. Төзек дип саналган комбайннарның шактые сугуда эшли алмаячагы да борчулы хәл.

Дөрес, район хакимияте хуҗалыкларның комбайн паркын тулыландыру һәм ныгыту буенча эшлекле чаралар күрә, әмма бит куәтле яңа техника да, мобиль җыелма отряд та беренче чиратта уңышы мул булган ишле участокларга озатылачаклар, шуңа күрә хуҗалыкларның үзләрендәге бар техникага да эш җитәрлек булачагын онытмаска кирәк. Кызганычка каршы, кайбер хуҗалыкларда бүгенгәчә иясез комбайннар да бар әле. Урак техникасы дигәндә бу эштә кулланылачак барлык машиналар комплексы да күздә тотылырга тиеш. Шуңа күрә ашлык ташуда катнашачак техниканың, ындыр табаклары, ашлыкны киптерү һәм чистарту агрегатларының төзеклеге турында да ашыгыч кайгыртмыйча булмый.

Быел уракка әзерлекнең йомшаграк баруы терлек азыгы хәзерләү, аерым алганда күпьеллык үләннәрнең беренче катын чабып алу озаккарак китү белән дә аңлатыла. Анысы сузылу исә уңышның елдагыдан мулрак булуыннан гына түгел, ә аерым очракларда оешмаганлыктан да. Терлек азыгы хәзерләүнең беренче этабын тиз арада тәгәлләмәсәк, ул эшнең уракка ялганып китәчәге көн кебек. Шуңа да авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе башлыгы Р.М.Гыйбадуллинның киңәшмәдә ясаган чыгышы иң элек шушы мәсьәлә хакында иде, ул шулай ук терлекчелек, аерым алганда сөтчелек һәм дуңгызчылык тармакларын көндәлек күз уңында тоту зарурлыгы турында да ассызыклап үтте.

## Кайда савым ишле?

### Саннарның беренче баганасы - алты айда, икенчесе - июньдә бер сыердан савылган сөт (килограммнарда).

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Дуслык» | 3583 | 690 | «Татарстан» | 1676 | 354 |
| «Кондырча» | 3392 | 762 | Кузнецов исем. | 1648 | 440 |
| Мичурин исем. | 2665 | 1806 | Сөт - май комб. ярд. хуҗ. | 1609 | 443 |
| «Агрохимсервис» ярд. хуҗ. | 2372 | 560 | Нефтебаза ярд. хуҗ. | 1562 | 365 |
| «Рассвет» («Норлат» а/ф) | 2259 | 495 | «Заря» | 1535 | 364 |
| «Якты Күл» («Норлат» а/ф) | 2125 | 529 | «40 лет Победы» | 1519 | 410 |
| Хафизов исем. | 2089 | 472 | «Үрнәк» | 1477 | 344 |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 2060 | 449 | РСУның ярд. хуҗ. | 1464 | 739 |
| «Заветы Ильича» | 1960 | 436 | «Таң» | 1317 | 372 |
| «Родина» | 1953 | 418 | «Игенче» | 1296 | 286 |
| «Чирмешән» | 1898 | 428 | «Әлмәт» | 1294 | 333 |
| Муса Җәлил исем. | 1892 | 440 | МСОның ярд. хуҗ. | 1230 | 276 |
| «Киекле» | 1870 | 469 | «Алга» | 1176 | 324 |
| Синдряков исем.(«Норлат» а/ф) | 1766 | 420 | «Комбайн» | 1066 | 274 |
| «Төрнәс» | 1679 | 357 | Район буенча. | 1744 | 413 |

Быел алты айда бер сыердан савылган сөт узган елның шул чорындагыдан 509 килограммга күбрәк булды. «Кондырча»да, шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгында, «Якты Күл»дә бу чорда малларның продуктлылыгын 1097 - 1321 килограммга арттыруга ирештеләр. (Ә бит саннарга күз салсак, арада сыерлары алты ай буена уртача шулкадәр генә сөт биргән хуҗалыклар да бар әле). Шулай да ярты еллыкны һәр хуҗалыкның узган елгыдан күпкә яхшырак нәтиҗәләр белән тәмамлавы куандыра.

Июньдә дә район буенча савым узган елның шул чорындагыдан 119 килограммга артыграк булды. Мичурин исемендәге, «Якты Күл». «Кондырча» хуҗалыкларында, «Агрохимсервис»ның ярдәмче хуҗалыгында бу аерма 180 - 190 килограмм тәшкил итте.

## Мактаулы исем

***Авыл хуҗалыгы производствосында икътисадый эш өлкәсендәге казанышлары өчен Октябрь районының Синдряков исемендәге крестьян һәм фермер хуҗалыклары ассоциациясе баш бухгалтеры Надежда Ивановна Храмовага «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирелде.***

# Дуслар белән тормыш узган «Дуслык», Дуслар белән гомер кичерә

## Киңәшче дә, ярдәмче дә...

Н.Мусин. Даими укучыларыбыз газета битләрендә шушы фамилия белән бирелгән язмаларның шактый еш күренүен билгеләрләр.Кем соң ул,журналистмы, хәбәрчеме дигән уй башларына керми калмыйдыр, мөгаен. Язмаларның эчтәлекләре белән азмы-күпме таныш булган кешеләр белә булыр: Н.Мусин-журналист түгел,ә үзенчәлекле бер хәбәрче.

Нургали Мингалиевичның «Дуслык» белән дуслыгы сиксәненче еллар уртасында, ул район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә игенчелек бүлеге начальнигы итеп билгеләнгәч башланды.

Аңа кадәр Минзәләдә техникум бетереп кайтып, Югары Норлат авылында баш агроном булып эшләгән, читтән торып Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган иде. Бәлки, ул вакытта да аның газета белән хезмәттәшлек итәргә теләге булгандыр.Әмма үзе әйтүенчә, безнең «Дуслык»ны яшьтән үк көтеп алып, кызыксынып,яратып укыган.

-Нургали Мингалиевич, пресс-үзәк өчен мәгълүматлар кирәк...

-Басуга рейд үткәрәсе иде...

-Технологик эз калдырып чәчүнең өстенлегенә нигезләмә бирә алмассызмы икән?

-Нургали абый, көзге чәчү җитә. Район игенчеләре алдына аның быелгы бурычларын билгеләүче белгеч язмасы бирәсе иде газетада. Яза алмассызмы...

Шундый һәм авыл хуҗалыгы, аерым алганда игенчелек тармагына кагылышлы тагын әллә ни кадәр сорау бирмәгән көнебез бик сирәк безнең аңа.Нургали абыебызның вакыт юклыкка сылтап яисә башка сәбәпле сорауларыбызны җавапсыз калдырганы юк әлегәчә.Мәгълүматларны да табыштыра,һичнинди тоткарлыксыз башка сорауларга да төгәл җавап бирә.Белгеч язмасы таләп ителгәндә, аны язып бирергә дә булдыра.Ә ул язган әйбергә, кем әйтмешли,черки борынын тыга алмый инде: конкрет та,профессиональ дә,шул ук вакытта газета телендә дә була ул.

Газета укучы Н.Мусин вакытлы матбугат битләрендә мәкаләләр бастыру белән генә шөгыльләнә дип уйламасын тагын. Районда ул агрономия белгече буларак та абруйлы әле.Оста бүлек җитәкчесе буларак та хөрмәтләнә Нургали Мингалиевич:бергә хуҗалыкларда булганда аның җирдә үсүче бер генә нәрсәгә дә битараф булмавын еш күзәтергә туры килгәне бар. Тегe яки бу хуҗалыкта җирләрнең потенциаль мөмкинлекләре,бүгенге көндәге ситуацияне яхшы белә ул, саннар белән дә реаль эш итә. Кисәтү-киңәшләре исә һәрчак нигезле була.

Тулаем районның игенчелек тармагы өчен җаваплы кешесе буларак документлар-план-сметалар, төрле мәгълүматлар белән эш итәргә туры килә Нургали Мингалиевичка. Ә аларның төгәллеге, пөхтәлегенә күпләр сокланырлык. Газета өчен теге яки бу сан кирәк булып Мусинга мөрәҗәгать итсәң, аны һичшиксез табып була инде.

Газета хәбәрчеләр белән көчле,аларның язмалары белән кызыклы. Н.Мусин да аны кызыклы, эчтәлекле итүчеләрнең берсе.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Олы җанлы Нина апабыз

Сабыр адымнары белән салмак кына редакция бусагасыннан күтәрелә. Тыныч, гади рус хатыны... Бәхәсле очракларда теләсә нинди авыр сүзне эченә йотып, тагын да сабырланып калгандай була. Яманны искә алып һичкемне рәнҗетмәс, бары тик хәленә кереп теләктәшлеген генә белдерер.

Район газетасын чыгаруга гомерен багышлаган машинистка Нина Ивановна Кубасова хезмәттәшләренең күңелендә менә шундый итеп саклана. Хәер, Нина Ивановна дип түгел,якын үз итеп Нина апа дибез без аңа. «Дуслык»ның 66 елының яртысыннан артыгы аның белән бергә чыккан, бу шул еллардагы газеталарның һәрбер тыныш билгесенә кадәр аның кулы аша үткән дигән сүз.Юк, кулы гына түгел,йөрәге аша үткәндер, мөгаен...



Нина Ивановнаның җылы рухлы, олы күңелле сыйфатлары белән бергә, югары дәрәҗәдә һөнәри осталыкка ия булуы да коллегаларында соклану уята иде.Аның белән озак еллар эшләп,дусты, сердәше булган корректорыбыз Наталья Русакова менә нәрсә сөйли:»Гаҗәеп оста машинистка иде Нина Ивановна.Искиткеч зур тизлек белән,грамоталы итеп басарга сәләтле». Эш күләменең зурлыгы аркасында, өзлексез басу аның өлгер, җитез бармакларын шулкадәр автоматик көйгә сала ки, алар хаталануны да белми үз эшләрен башкаралар.Тәҗрибәле машинистканы күрми калмыйлар: аның язу машинкасы янына яңадан-яңа язмалар, мәкаләләр һәм газета өчен генә түгел, ә шәһәрнең башка учреждениеләре өчен дә эшлекле кәгазьләр өелә тора. Соңгылары, әлбәттә, бушлай, шуңа карамастан, йомшак,күндәм табигатьле Нина Ивановна берсен дә кире бормый, аерым сүз кузгатмый, эшли дә эшли.Пенсия яшенә җитәрәк аны һөнәри чиребуыннар сызлавы интектерә башлагач, аны корректор итеп күчерәләр. Бу юлы да ул үз эшен намуслы башкара.

Үзенә карата зур таләпчәнлек тойса да, чордашлары кебек үк һичнинди таләпсез Нина Ивановна. Шәхси гаилә тормышы Южная урамының бер агач йортында кайната-кайнана оясында үтә.Шунда дүрт бала-бер кыз һәм өч малай туып үсәләр. Пенсиягә чыкканда гына Нина Ивановнаның ире, гомер буе НУРБ да эшләп ялга киткән җор холыклы Иван Кубасовка бер бүлмәле фатир бирелә.Хәзер инде икесе дә пенсиядә, әби белән бабай салкын кышларын әлеге бүлмәгә килеп яшәсәләр, яздан көзгә кадәр күпне күргән өйдә үткәрәләр.

Түземле, оптимистик рухлы, олы җанлы Нина Ивановнаны язмыш бик каты сыный, балалар тормышы аша кайгыларын, хәсрәтләрен туйганчы бирә. Эчке кичерешләр, уйлар, борчылулар тулы бер көне дә олы романга тиң аның... Шуңа карамастан, Нина Ивановнаның рухын сындыра алмады язмыш. Яшәүгә, кешелеклеген җуймыйча тормыш итүгә омтыла ул һаман да.

Ә без, аның хезмәттәшләре, Нина Ивановнаның шатлыгын да, кайгысын да уртаклашырга һәрчак әзербез, гомумән, аның сабыр гына, салмак адымнар белән редакция бусагасыннан атлап керүенә шатбыз.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

**Рәсемдә: Н.Кубасова (сулдан беренче, утырган) хезмәттәшләре - редактор урынбасары Г.А.Давыдова, тәрҗемәче Р.Б.Гайфетдинова, корреспондент А.П.Пестова белән. 1977 ел.**

## КАЛӘМДӘШЛӘР

- Федор Антонович, пенсиядә ни белән шөгыльләнергә җыенасыз? - дип сорадым мин күптәнге иптәшемнән.

- Әлегә җитди итеп уйлаганым юк,- дип җавап бирде ул. - Иң әүвәл кайда яшисемне хәл итәргә кирәк. Казанга күчәрмендер ахры.



- Бу бик әйбәт булыр,- дип хупладым мин - ниһаять сезнең тарихи материаллар туплау мөмкинлегегез булачак. Бу хат алышу түгел. Анда Дәүләт архивы бар.

Мин Федор Антонович Михейкинның Якушкино урта мәктәбендә тарих укытканда җирле материаллар кулланырга тырышуын искә төшердем. Аның дәресләре бик кызыклы үтә иде. Үзем тарих укыта башлагач та аның тәҗрибәсе миңа бик ярап куйды.

- Безнең район буенча архив материалларын «Дуслык»ка, Норлат музеена җибәрегез,- дидем мин. - Ә мин хәлемнән килгәнчә шигырьләр, хикәяләр язып торырмын.

Без ниятләгәнне гамәлгә ашырдык. Федор Антонович, архивтан файдаланып безнең генә түгел, Аксубай районының да байтак авылларының тарихын җентекләп язды. Аларның кайберләре район газетасында да басылды.

**Ф.САВГАЧЕВ.**

**Рәсемдә: крайны өйрәнүче Ф.А.Михейкин, язучы Ф.А.Савгачев.**

## Россиянең хәрби дан көннәре

# «УРА! БЕЗ ҖИМЕРӘБЕЗ... ШВЕДЛАР БӨГЕЛӘ»

10 июль- Петр I командалыгы астында рус армиясенең Полтава көрәшләрендә шведларны җиңү көне (1709 ел).

1799 елның апрелендә Карл XIIнең швед гаскәрләре, Россиягә бәреп кереп, Полтавага һөҗүм башлыйлар. Шәһәр гарнизоны берничә штурмны уңышлы кире кайтара. Май ахырында Полтавага Петр I җитәкчелегендә рус армиясенең төп көчләре килеп җитәләр.Хәрби советта генераль көрәш бирергә карар кылына.

Рус гаскәрләре Полтавадан 5 км. төньяктарак ныгытылган лагерьга урнашалар, 10 редуттан алдынгы позицияләр оеша. Алар артыннан Меньшиков командалыгында кавалерия полклары урнаша.

Карл XII рус гаскәрләрен җиңеп, шуның белән Төркияне Россиягә каршы көрәшкә күтәрергә ният тота.Атака өчен 20.000 кеше бүленә.

Швед пехотасы 4 колонна булып рус гаскәрләренә каршы юнәлә, алар артыннан 6 колонна атлы гаскәр бара. 2 сәгатькә сузылган каты көрәшләрдән соң алар 2 редутны җиңүгә ирешәләр. Алар арасында хәрәкәт итеп, артиллерия һәм кораллы һөҗүмгә әлгәләр.

Петр I армиянең төп көчләрен ныгытылган лагерьдан чыгара. Кул сугышы китә. Рус атлы гаскәрләре дошманның флангларын ала башлый.

Шведлар, камап алудан куркып, тизрәк чигенә башлыйлар. Атлар аларны эзәрлекләп китәләр, таркалган швед армиясе сугышчыларын әсирлеккә алалар.

Карл XII һәм Мазепа зур булмаган отряд белән көчкә Төркиягә качып котылалар. Шведларның 9 меңнән артык сугышчысы үлә, 18 кешедән артык кеше, корал һәм йөкләре әсирлеккә алына. Руслар 1345 сугышчыны югалталар.

Полтава көрәшләре нәтиҗәсендә Швециянең хәрби куәте җимерелә, Төньяк сугыш (1700 - 1721) руслар файдасына хәл ителә.

**Язманы И.Сандлер әзерләде.**

# ИКЕСЕНӘ БЕР ИСЕМ: ИГЕНЧЕ!

Бу ике кешенең бергәләп рәсемгә төшүенең инициаторы аларның олысы булды. Газета укучыларыбызның күпчелегенә яхшы таныш Вәлиулла Хөснуллович Шәйхетдинов белән яшь булса да, инде исеме дә газетабызда еш телгә алынып, рәсеме дә бирелгәләгән Әхәт Гыйниятуллин бу юлы сабанчыларның район конкурсында очраштылар. Конкурска алар икесе дә чакырулы иде. Игенчеләрнең олысын, районда иң өлкән, иң абруйлы һәм бай тәҗрибәле, заманында Россия Федерациясенең атказанган агрономы дигән югары исемгә лаек булган агроном буларак һәр елдагыча конкурсның комиссиясе составына чакырсалар, игенчелек тәҗрибәсе, механизаторлык стажы ягыннан үз яшьтәшләре арасында һичшиксез иң «өлкән»нәрдән саналырдай Әхәт исә бу бәйгегә әлегә районда бердәнбер булган сөрү агрегатына ия кеше сыйфатында килгән иде. Олысының гомерен игенчелеккә багышлап, шул олы һәм мактаулы хезмәттә яшәүнең ямен дә, тәмен дә тапкан, үз вазифасын ул эшләгән башта «Дружба», аннан Хафизов исемендәге колхоз районда бер югары игенчелек культурасы хуҗалыгы дип аталырдай дәрәҗәгә җиткереп башкарган игенче буларак конкурста кайсы гына механизаторның эшенә дә бер карауда тиешле бәяне куярлыгы бар һәм шуңа да мондый ярышларда комиссия члennары арасында аның сүзе иң абруйлы һәм күп очракта хәлиткеч тә була. Быелгы конкурста да Вәлиулла Хөснуллович механизаторларның җиренә җиткереп эшли торганнарының сөргән участокларына күңеле булып, иң гади таләпләрне дә санга сукмаучыларының кырны бозып, җирне азаплап йөрүләренә чын йөрәктән әрнеп йөргәнгә беренчеләренең күңелен дә күтәреп җибәрергә, ә икенчеләренә йомшак кына иттереп тә бик каты әйтергә тулы хакы бар иде өлкән игенченең. Үзе баш агроном булып эшләгән елларда хуҗалыктагы һәр кырны, һәр культураны игътибар үзәгендә тотып, технология таләпләренең җиренә җиткереп үтәлүенә ирешү җәһәтеннән һәр механизаторның җаен - көен дә, кайсының нәрсәгә сәләтле икәнлеген дә энәсеннән җебенә кадәр белеп торган игенче шул ул. Әле менә кемнең нәрсәгә сәләтлелеге дигәннән, шушы конкурска чакырылган Әхәт Гыйниятуллин белән бергәләп рәсемгә төшәргә теләве дә юкка гына түгел иде. Сигезне бетерер - бетермәс тракторга утырып эшли башлаган, корыч атның төрлесен иярләгән егеткә куәтле К-700 тракторларының чыккан гына заманында шул техниканың ышанып тапшырылуын һәм Әхәтнең әле ул чакта аңарда эшләү өчен махсус курсларда укып чыгу соралган шул катлаулы техниканың да серенә тиз төшенеп, шуңарда менә дигән иттереп эшләп китүен яхшы хәтерли икән Вәлиулла абый. Шул елларда хуҗалыкта беренче К -700 янында бергәләп рәсемгә төшкән булганнар алар һәм шул рәсем күңеләмә иң хуш килгән ике рәсемнең берсе ди ул. (Тагын берсе агрономның күкрәккә җиткән арыш арасында төшкәне икән). Һәм менә ике игенче тагын бергә, бу юлы инде районда бер (республикада да ике генә) америка тракторы белән француз сабаныннан торган сөрү агрегаты янында. Зурлыгы ягыннан «Беларусь» чамалы гына булып, куәте буенча теге К- 700ләргә бирешмәүче бу яңа төр техниканың нәкъ менә Әхәт кулына ышанып тапшырылуы очраклы түгел иде һәм егет ул ышанычны, кем әйтмешли, бише беләнаклады. Узган ел үз хуҗалыкларында да, күрше «Большевик»та да (хәзер инде анысы шушы хуҗалык составында) әллә никадәр җир сөрде ул, башка төр кыр эшләрендә дә катнашты. Һәм шул искиткеч трактор, әйләнмәле сабан белән җир сөрүнең ничек булуын күрсәтү өчен сабанчыларның район конкурсына да килде. Механизаторларның бу агрегатны моңарчы күргәне булмаганнары аның эшләвен дә, сөрелгән җиренең сыйфатын да зур кызыксыну белән карадылар. Дөрес, хикмәт техникада гына түгел, аның ышанычлы, ипле механизатор кулында булуында да. Ә Әхәт Минәхмәт улы Гыйниятуллин үз куллары белән җыеп - көйләп чыккан сабанны да, бездәгеләрнең дистәсенә биргесез тракторны да бик кадерләп, кушылган бар таләпләрне үтәп карап кына тора.

Берсе гомере буе җиргә намуслы хезмәт итеп дан һәм хөрмәт казанган, икенчесе аңардан бермә - бер яшьрәк булса да техника серен, җир кадерен белеп эш итүче ике игенченең икесе өчен дә истәлекле һәм кадерле булачак тагын бер фоторәсемнең тарихы әнә шундый.



**Р.МУЛЛИН.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

# Әй, шофер, рульне тот туры!

Шофер һәрчак юлда инде ул. Кайчак кыска вакытлы ремонтка тукталганда да күңеле кыбырсый, ерак сәфәрләргә күнеккән йөрәге юлга ашкына. Шуңа да чын шоферлар һичкайчан гараж - мастерскойда үткәрми вакытын. Әгәр дә була икән инде, анысы да техник карауга гына. Ә менә узган атнада УТТ транспортчылары бөтенләй башка сәбәпле буш үткәрделәр вакытларын: бирeдә идарә шоферлары арасында һөнәри осталык конкурсы үтте. Ә аның максаты бик изге иде: идарәнең структур подразделениесе хезмәткәрләренең иҗат активлыгын күтәрү, производство дисциплинасын яхшырту, иң яхшы автомобиль йөртүчеләрне ачыклау.

Конкурс 2 этапта үтте. Шуның беренчесе теоретик иде. Комиссия әгъзалары шоферларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен ничек белүләрен тикшерделәр. Икенчесе исә практик булды. Төрле маркалы машиналарда эшләүчеләр тиз һәм шул ук вакытта фигуралы йөртү күнекмәләрен күрсәтергә тиешләр иде.

Әйтергә кирәк, конкурска зур хәзерлек белән килделәр шоферлар һәм ул оешканлык белән үтте дә. «КамАЗ» автомашинасы шоферлары арасында беренче колоннадан Хәбир Булатовтан да оста йөртүче булмады машинасын. Өстәвенә, кайгыйдәләрне дә яхшы белә булып чыкты.

Шул ук колоннадан Александр Антонов һәм бишенчедән Фаил Моратов икенче һәм өченче урыннарны бүлештеләр.

ЗИЛлар да мәйданда выжлап йөрделәр ул көнне. Җиңүчеләрнең исә барысы да беренче колоннадан булдылар. Валерий Малейкин беренче, Руслан Туишев - икенче, Шамил Гыйльманов өченче булдылар конкурста.

Аннан соң «ГАЗ - 66» автомашиналарында эшләүчеләр көч сынаштылар. Беренчелекне алтынчы колоннада эшләүче Анатолий Никифоров һичкемгә бирмәсә, калган ике призлы урынны дүртенче колонна егетләре Алексей Иванов һәм Николай Волков бүлештеләр.

Алга таба исә алтынчы колонна егетләре өлгерлек күрсәтте. «УАЗ»лар шоферлары конкурсында, мәсәлән, шул коллективтан Геннадий Парфенов икенче урынны яуласа, «КАВЗ» автобусларын йөртүчеләр арасында беренчелекне Рамил Сөләйманов, икенче урынны Илгиз Нуруллин, өченчене Фоат Әхмәтов яуладылар. «УАЗ» шоферлары арасында исә беренче урында Николай Аланов, өченчедә Равил Әюпов булдылар.

Конкурс тәмам. Комиссия әгъзалары аларның нәтиҗәләреннән канәгать калдылар һәм шундый бәйгеләрне әйдәп баручы һөнәр кешеләре арасында гына түгел, ә башкалар арасында да үткәрергә кирәк дигән нәтиҗәгә килделәр. Бер яктан шундый чаралар һөнәр осталыгын камилләштерүгә ярдәм итсә, алар дисциплинаны күтәрә, коллективны уртак бер максатка да туплый. Менә бу юлы да катлаулы бәйгедә көч сынашып һәм призлы урыннар яулап, кулларына истәлекле призлар тоткан егетләрнең йөзләрендәге шатлыкны күрсәгез икән сез! Хәбир Булатов исә моңа сөенде дә, бераз көенде дә. Шулай булмый ни: «Татнефть» АҖе шоферлары арасында үтәчәк һөнәри осталык конкурсында катнашып, Норлат УТТсы данын яклыйсы бар бит әле аның!

**Р.МИНАПОВА.**

## ХӘЕРЧЕМЕ СИН? УЙЛА!

Совет чорында гел «бер төскә буялган» ил гражданнарының тормышы да бер чамадарак булса, бүген Россияне җан башына туры килгән керем буенча күп төрле төсләргә бүләргә мөмкин. Иң рәхәт тормышта яшәүчеләр Мәскәүдә - биредә җан башына аена 3 миллион сумнан артыграк керем туры килә. Бу - яшәү минимумыннан 8 мәртәбә артыграк дигән сүз. Иң күп алучылар рәтенә Ямал - Ненец, Ханты - Манси, Чукотка автономияле округлары, Төмән һәм Красноярск өлкәләре, Якутия керә.

Икенче төркемгә, ягъни хәерчелек сызыгыннан 2 - 3 мәртәбә күбрәк алучы төбәкләргә Санкт - Петербург, Орел, Самара, Пермь өлкәләре, Татарстан, Карелия һәм Коми республикалары кергән.

Хәерчеләр төркеменә керүчеләр - Бурятия, Таулы Алтай, Хакассия, Алтай, Новосибирск, Чувашия, Тамбов, Пенза, Курск, Түбән Новгород, Киров, Мәскәү, Владимир өлкәләре... Бу исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде.

## Эшсезләр дикъкатьсез калмас

Татарстан Министрлар Кабинеты 1997 елга эшсезләрне эшле итүгә булышу һәм социаль яклау программасын раслады. 1996 елда шундый программа булдыру эшсезлек дәрәҗәсен хезмәткә яраклы халыкның 2,4 проценты тирәсендә тотарга мөмкинлек бирде.

Икътисадтагы кыенлык республика оешмаларыннан, предприятиеләрдән эшче - хезмәткәрләрне бушатуга китерә. Яңа программа эшсезлекне республика халкының 3,5 проценты чикләрендә тотарга, 400 мең кешене эштән аермаска, 28 мең эшсезне хезмәткә урнаштырырга мөмкинлек бирер. Эшсезләргә яңа һөнәр бирү һәм хезмәткә урнаштыру да игътибарда булачак, 1300-дән артык яңа эш урыны хасил итү, 6,5 мең эшсезне җәмәгатьчелек мәшәкатьләренә тарту күздә тотыла.

## Иссәләр дә заман җилләре

Татар милли университеты үзенең дүртенче уку елын каршыларга җыена. Ниһаять, аның да бәхет кояшы балкыды: милли уку учагына элекке балалар бакчасы бинасын бирделәр. Бу исә яңа уку елында тагын ике яңа белгечлек бирү бүлеге ачу мөмкинлеген тудыра: тарих һәм социаль психология факультетлары. Монда хәзер биш факультет бар.

## Ислам дөньясы дәшәдер

Казан дәүләт технология университетының гуманитар мәгариф кафедрасында гарәп теле һәм мөселман дөньясы мәдәнияте бүлеген тәкъдир итү тантанасы булды. Аны быел өстәмә белем бирү бүлеге буларак, АКШ һәм Согуд Гарәбстанының «Таибә» дип аталган халыкара оешмасы белән берлектә ачкан иделәр. Һәм менә бездә дә Ислам дөньясының мәдәнияте, гореф - гадәтләре, теле һәм философиясен тирәнтен өйрәнү мөмкинлеге барлыкка килде.

## Бу - кызыклы

# Листьевны кем үтергән?

Сорауны «нәрсә үтергән?» дип куеп, «акча үтергән» дип җавап бирергә туры килмәгәе. «Общая газета» журналистлары белән бер очрашу вакытында Русиянең Генераль прокуроры Ю.Скуратов: «Листьев эшен тикшергәндә сюрпризлар күп булыр»,- дигән иде. Әлеге сюрпризларның берсе - мәрхүмнең акчага мөкиббән китүе белән бәйләнешле хәлләр булырга тиеш. Яңа мәгълүматларга караганда, В.Листьев 1994 елда ук Израильгә дипломат - дипломат долларлар ташый башлаган. Таможня хезмәткәрләре әйтүенчә, 100 долларлыклар тутырган гадәти дипломат 16 кг.га тарткан һәм сумма 1 млн. доллар тәшкил иткән. Һәр алып чыгуында В.Листьевның дипломаты 10 кг.нан артык авырлыкта булган. Шереметьево аэропортында бу фактлар теркәлсә дә, ни хокук сакчылары, ни таможня хезмәткәрләре шул кадәр сумманың каян килүе, кая китүе белән кызыксынмаганнар. Әлеге миллионнарның декларациягә дә язылмавын әйтсәк, В.Листьев ачыктан - ачык контрабанда белән шөгыльләнгән булып чыга.

Инде якын тарихка кире кайтсак, әле СССР исән - имин чакта ук Останкинода «Москва - Глобальная» дигән спутник системасы оештырылган була. Чит илләргә сибелгән совет илчелекләре шуның аркылы Мәскәү тапшыруларын карыйлар. Соңрак ОРТ әлеге системаны Израильдә яшәүче урыс эмигрантлары өчен Русия телетапшыруларын күрсәтүдә файдаланмакчы була. Әлбәттә инде «Израиль - Русия проекты» күп күләмдә рекламалар әйләндерүне дә планлаштыра. Кайбер чыганаклардан мәгълүм булганча, Русия һәм Израиль «телемафиясе» арасында сугыш нәкъ менә әлеге рекламалар тирәсендә башланып киткән, чөнки кайда реклама - шунда акча. ОРТның продюссеры Олег СлабынькоＮың үтерелүен дә Израиль проекты белән бәйлиләр, чөнки ул әлеге проекттан читләшергә, качарга теләгән һәм шул нигездә Листьев белән бик каты ызгышкан булган. Димәк, ничек кенә борма, Листьевны үтерү «телебизнес» белән бәйләнгән булып чыга.

Хәзер тикшерү эшләре тәмамланып килә.

Кайбер газеталар хәбәр итүенчә, үтерүчеләр билгеле. Әмма заказ бирүчеләрнең кем икәнен прокуратура хәбәр итәрме, юкмы? Чөнки эш бик эчкәре киткән булырга охшый. Ю.Скуратов әйтмешли, В.Листьевның эшмәкәрлеге, аның алдында торган каршылыклар турында танышлары, хезмәттәшләре сөйләргә теләмиләр, сорау алуга да килмиләр...»

**Р.ГЫЙЛЕМХАНОВ.**

**(«Татарстан яшьләре» газетасының 26 нчы июнь санынннан).**




## Сатабыз

**Фрунзе урамында 12 номерлы ике янәшә йорт, 10 сутый бакча. Гаражы, мунчасы, коесы, базы белән сарае бар, газ кертелгән.** 40 лет Октября ур., 14 йортка мөрәҗәгать итәргә.

***

**1991 елгы ВАЗ - 2106**. Тел.: 4 - 42 - 59.

***

**Ашыгыч рәвештә «Москвич - 412», кыйммәт түгел**. Тел.: 2 - 14 - 25.

***

**4,5 х 3 метрлы чанада гараж - 2 млн. сум, «Алмалык»та дача участогы, 6 сутый - 1 млн. сум**, **Тотылган йомшак мебель - 1 млн.сум.** Тел.: 2 - 17 - 99.

***

**1996 елгы ак төстәге ВАЗ - 21213,** К.Маркс урамында ателье бинасында урнашкан «Вито - Авто» «Автозапчасть» кибетенә мөрәҗәгать итәргә.

***

**Шикәр заводында 1 бүлмәле фатир.** Тел.: 2 - 21 - 95.

***

**Йомшак мебель һәм ишекләр**. Тел.: 2 - 29 - 83.

***

**Бер бүлмәле фатир**. Казандагы тел.: 56 - 34 - 69.

***

**«Нива» автомашинасы.** Адрес: Красноармейская ур., 61а - 13.

***

**«Нива» ВАЗ - 2121**. Адрес: Советская ур., 189 - 93.

***

**Ашыгыч рәвештә кухня гарнитуры (2650), прихожая, «SONI» тумбалары, Германиядә эшләнгән одеяллар (225), «PANASONIK» телевизоры (1550), «Пилот» күн курткасы (850). Бар да арзан**. Тел.: 5 - 17 - 79 кич белән. Таныклык номеры 20659.

***

**Бер бүлмәле фатир һәм «Алмалык»та бакча участогы.** Адрес: Советская ур., 189 - 21, 17.00 сәг.тән соң.

***

**Шәһәр уртасындагы яңа йорттан хосусыйлаштырылган ике бүлмәле фатир**. Белешмәләрне 2 - 15 - 63 телефоны аша редакциядән ала аласыз.

***

## Төрлесеннән

**Бурычка акча алам.** Тел.: 2 - 22 - 97.

***

**«Норлат - Октябрь ит комбинаты» АҖсенә даими эшкә**

**- газ һәм электр белән эретеп ябыштыручылар;**
**- технологик җиһазлар ремонтлау буенча слесарь;**
**- тракторчы;**
**- техник фабрикатлар цехы аппаратчылары;**
**- ярдәмче эшчеләр кирәк.**

Кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә.

***

**Октябрь район кулланучылар җәмгыятендә сатуда:**

**1. 1,25 х 2,75 метрлы ДВП - 26000 сум яки иткә алмашка.**

**2. Идән такталары (нарат) бер куб. метры 550000 сум.** Белешмәләр өчен директорга мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 2 - 21 - 15.

***

**Хәбибуллин Тәлгать Хикамдинович исеменә машина йөртү таныклыгы табучыны бүләк бәрабәренә иясенә кайтаруын сорыйбыз.** Тел.: 2 - 20 - 28.

***

**Зүзәй нефть промыселы каршындагы яңа 37 нче Әлмәт төзү - монтаж участогына тиз арада ташчылар, балта осталары, бизәүчеләр, эретеп - ябыштыручылар кирәк. Хезмәткә түләү - эш башыннан**. Зүзәй нефть промыселына мөрәҗәгать итәргә.

***

**Булатов Рамил Хасиятуллаевич исеменә документлар салынган кара сумканы бүләк бәрабәренә** Заводская ур., 25 - 7 адресы буенча иясенә бирүләрен сорыйбыз.

***

**2 нче мәктәп тарафыннан Мокина Инна Анатольевна исеменә бирелгән А 1292247 номерлы өлгергәнлек аттестатын югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

## Табылдыклар өстәле

***«Теремок» балалар бакчасы янында ачкычлар бәйләме табылды. Югалтучы редакциянең реклама бүлегенә мөрәҗәгать итсен.***

## Спорт • Спорт

## РЕСПУБЛИКАДА ИКЕНЧЕ

Инде газетада хәбәр иткәнебезчә, «Күн туп» призына үткәрелгән ярышларда Октябрь районы яшь футболчылары командасы Чистай шәһәрендә үтәчәк финал ярышларында катнашу хокукын яулаган иде. Июнь азагында районыбызның яшь спортчылары ул ярышларда катнаштылар. Чистайда үткән бу чарада Бөгелмә, Әлмәт, Зеленодольск, Чистай шәһәре командалары бар иде.

Безнекеләр башта чистайлылар белән уйнады. Егетләребезнең кәефе көр иде, әмма беренче булып уйнаудан дулкынланулары чамадан тыш булды. Шулай да үз - үзләрен тиз кулга ала алдылар алар. Беренче тупны Дима Киселев кертте. Уен исә норлатлылар файдасына 7 : 1 исәбе белән төгәлләнде.

Республикада көчлеләрдән саналган Бөгелмә футболчылары белән уйнау да зур осталык таләп итте. Беренче ун минутта уен тигез барды, әмма беренче таймда безнең саклаучыбызның гаебе аркасында бөгелмәлеләр уңыш яулады.

Икенче таймда Илшат Гайнуллинның капкага керткән тубы нәтиҗәсендә исәпләр тигезләшкән дә иде, уен тәмамланырга берничә минут калгач, көндәшләр безнең капкага тагын бер туп кертеп, өстенлек алдылар.

Икенче көнне безнең егетләргә икенче тапкыр Әлмәт командасы белән уйнарга туры килде. Норлатта үткән зона ярышларында безнең команда аларны 3 : 0 исәбе белән җиңгәннәр иде инде. Әлмәтлеләр финал ярышларына үз командаларын шактый «ныгытып» килгәннәр булуы күзгә бәреп торырлык иде. Әмма моңа да карамастан, безнең егетләр Норлат командасының көчле булуын тагын бер кат расладылар.

Финал ярышларының соңгы көнендә безнең футболчылар Зеленодольск командасы белән уйнадылар. Беренче тайм азагында безнең ярым сакчы Динар Миннегалиев көндәшләр капкасына туп кертте. Уен 1 : 0 исәбе белән төгәлләнде. Шулай итеп, Норлат футболчылары республика финал уеннарында лаеклы рәвештә II урын яуладылар.

Соңыннан футболчылар парадында җирле хакимият вәкилләре безнең уенчыларны кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләде.

Гомумән, яшь спортчыларыбыз әлеге уеннардан канәгать калдылар. Моның өчен безнең бүгенге авыр заманада да командабызны ярышка җибәрү өчен матди ярдәм күрсәткән район хакимиятенә рәхмәтебез зур.

**А.ХАРДИН.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

*Кадерле сеңелебез* ***Сәрия Габбас кызы Галиеваны*** *юбилее белән тәбрик итәбез.*

*40 яшь тулган көнең белән,*
*Чын күңелдән, Сәрия, сине котлыйбыз.*
*Исән - саулык, озын гомер,*
*Тигез тормыш сиңа телибез.*
*Озын гомер бирсен ходай сиңа,*
*Сызламасын аяк - кулларың.*
*Сау - сәламәт узыйк бергәләшеп*
*Борма - борма тормыш юлларын.*

***Апаларың Ралия, Фәүзия, Фәрбизә, абыең Мансур һәм җизнәләрең, киленнәр.***



**Аксеновның бизнес мәктәбе 1997 - 98 уку елына түбәндәге белгечлекләр буенча укучылар туплый:**

**- бухгалтер - экономист - 1 ел.**

**- бизнес оештыру мастеры - 5 ел. Уку бәясе 1 августка кадәр 740 мең сум. Шулай ук компьютердан файдалану курсларына (торып уку) укучылар туплыйбыз**. Адрес: Норлат шәһәре, Советская ур., 179, «53 нче СМУ» АҖсенең төп офисы, тел.: 2 - 15 - 61. Лицензия № Б 192008, 1996 елның 15 гыйнваренда бирелгән.

**Октябрь районы күптармаклы производство предприятиесе сүүткәргеч трассаны ремонтлау сәбәпле, Кормыш микрорайонында 9, 10 июльләрдә иртәнге 8.00 дән 21.00 сәгатькә кадәр су бирелмәячәге турында хәбәр итә.**

Администрация.

## Идел Буе региональ наркология үзәге

***Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.***

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне 1, 15 августта көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә. Заказ N 7195